| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ГЛАВА ЯКУШКИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЯКУШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |

Якушкино ав.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29 » март 2024 ел № 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Абрыскино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлеге башлыгы

КАРАР БИРӘ**:**

1. 2024 елның 11 апрелендә Абрыскино авылы, Гагарин урамы, 89 йорт адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында 10 сәгать 00 минутка элек расланганнарга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Абрыскино авылы гражданнары җыены билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Абрыскино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 24.11.2023 ел, № 3 карары;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Абрыскино Авылы торак пунктында гражданнар Җыенының 24.11.2023 ел, № 4 карары.

2. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

3.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Абрыскино авылында 24.11.2023 ел, № 3 торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карарның 1 пунктына үзгәрешләр кертергә ризамы, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Абрыскино Авылы торак пунктында гражданнар җыены узган дип танылсын, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

"Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Абрыскино авылы территориясендә теркәлгән, яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм уку йортларында көндезге уку формасы буенча белем алучы студентларның тол хатыннарыннан тыш, 2024 елда 1000(бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту кабул ителгән.

3.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Абрыскино авылы торак пунктында гражданнар Җыенының 24.11.2023 ел, № 4 карарына үзгәрешләр кертергә ризамы, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Абрыскино авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү чараларын кертергә, 1 гр инвалидлардан тыш., Бөек Ватан сугышы ветераннары Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, һәм уку йортларында көндезге уку формасы буенча белем алучы студентларның һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Абрыскино авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Якушкино авыл җирлеге башлыгы Х.Х. Хәмидуллин